**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2024 елның 19 июле 1167 номер

# КАРАР

## Күпбалалы гаилә статусын билгеләү турында

Россия Федерациясе Президентының «Күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы Указы нигезендә, күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары бирү һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Күпбалалы гаилә статусын билгеләү турында» 2024 елның 18 июнендәге 20-09/8480 номерлы хаты нигезендә Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының мәгариф оешмаларында күпбалалы гаиләләргә муниципаль хезмәтләр, ташламалар күрсәткәндә, федераль дәрәҗәдә таныклыкның бердәм үрнәге билгеләнгәнче, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Татарстан Республикасында күпбалалы гаилә статусын билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын билгеләү турында" 2012 елның 31 июлендәге 612 номерлы боерыгы белән расланган күпбалалы гаилә статусын билгеләү турында таныклык яисә карар нигезендә ташламалар һәм хезмәтләр күрсәтергә.
2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)
3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Г. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**